Атна саен мошенниклар, алдакчылар дия-дия кисәтәбез, ә алданучылар кимеми! Бәлкем без язганнар исегезгә төшәр, сак булырсыз. Пенсионер хатын стационар телефонга килешvнен гамәлдә булу вакытын озайту сылтавы белән мошенникларга 165 мен сум кvчергән.
Россия Эчке эшләр министрлыгынын ММО «Темниковский» га 63 яшьлек жирле хатын морәжәгать иткән, ул анардан ялган юл белән 165 мен сум урлау турында хәбәр иткән. Зыян кvрvче сvзләренчә, ана vзен элемтә хезмәтләре кvрсәтә торган телекоммуникация компаниясе хезмәткәре дип таныштырган билгесез кеше шалтыраткан һәм стационар телефонга килешvнен гамәлдә булу вакыты бетvе турында хәбәр иткән. Озакка сузмас очен СНИЛС номерын атарга кирәк булган: номерны атагач сойләшv тукталган. Озакламый пенсионеркага янәсе хәрби гарнизон вәкиленнән шалтырату килә: ул vз документынын номерын әйткән кешеләргә анын исеменнән ышаныч кәгазе рәсмиләштергәннәр һәм якын арада анын акчаларыннан файдаланырга, ботен акчаларын Россиядә тыелган экстремистик оешмага ярдәм итvгә юнәлтергә момкиннәр, дип хәбәр итә. Мондый хәлгә юл куймас очен ботен акчаны куркынычсыз счетка кvчерергә кирәк, ди. Монын очен пенсионер хатын-кыз әнгәмәдәше кушуы буенча Краснослободск шәһәренә китә, анда банкомат ярдәмендә билгесез кешегә диктантланган счетларга 165 мен сум кvчерә.